КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 15 ноябрь г.Казань № 1216

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар өлкәсендә төбәк мәгълүмат системасы турында» 2014 ел, 13 август, 585 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар өлкәсендә төбәк мәгълүмат системасы эшчәнлеге һәм аннан файдалану тәртибенә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар өлкәсендә төбәк мәгълүмат системасы турында» 2014 ел, 13 август, 585 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар өлкәсендә төбәк мәгълүмат системасы эшчәнлеге һәм аннан файдалану тәртибенә, 1.1 пункттагы «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар өлкәсендәге төбәк һәм муниципаль мәгълүмат системаларына карата бердәм таләпләр турында» 2013 елның 28 ноябрендәге 1091 номерлы карары белән расланган дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр» сүзләрен «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар,

эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар өлкәсендә контракт системасын мәгълүмат белән тәэмин итү, анда документлар әйләнешен оештыру буенча чаралар турында, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте актларының һәм актларындагы аерым нигезләмәләренең үз көчен югалткан дип тану хакында» 2022 елның 27 гыйнварындагы 60 номерлы карары белән расланган» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин